**Карар № 29**

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Советы карары

21 июль 2021 ел Түбән Бәрәскә авылы

**Санлы финанс активлары һәм санлы хокуклар турында мәгълүматлар тапшыру һәм Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Советының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 10 декабрендәге 778 нче номерлы Указын үтәү йөзеннән “Федераль законның аерым нигезләмәләрен тормышка ашыру чаралары хакында «Санлы финанс активлары, санлы валюта һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында», Әтнә районы прокуратурасының 2021 елның 24 маендагы 02-08-02-2021 номерлы «Муниципаль вазыйфалар биләүгә дәгъва итүче гражданнар тарафыннан керемнәр, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында белешмәләр, шулай ук, муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү турындагы Нигезләмәнең аерым нормаларына” карата бирелгән протестын өйрәнгәннән соң, Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. 2021 елның 30 июненә кадәр, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Түбән Бәрәскә авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүгә дәгъва кылучы гражданнар, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Түбән Бәрәскә авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар (муниципаль вазыйфа биләүче авыл җирлеге депутатларының һәм үз вәкаләтләрен даими булмаган нигездә гамәлгә ашыручы затлардан тыш) керемнәре, чыгымнары, милек һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга, Түбән Бәрәскә авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлегенә кертелгән затлар, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм аларны биләгәндә муниципаль хезмәткәрләр мөлкәти характердагы керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында белешмәләр, хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Советының 2016 елның 23 апрелендәге 25 нче номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъвалаучы гражданнар, Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлегенең муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлегенә кергән затлар һәм муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләнгәндә гражданнар керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук хатынының(иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиеш һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләр керемнәре, чыгымнары,

мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук хатынының(иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Советының 2017 елның 31 июлендә кабул ителгән 58 нче номерлы карары белән расланган, муниципаль учреждение җитәкчеләре вазыйфаларын биләүгә дәгъва итүче гражданнар, муниципаль учреждение җитәкчеләре вазыйфаларын биләүче гражданнар, «Керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында" Россия Федерациясе Президентының 2014 елның 23 июнендәге 460 номерлы Указы белән расланган белешмә формасы буенча тапшырыла торган белешмәләр белән бергә, хатыны һәм балигъ булмаган балаларына караган санлы финанс активлары, санлы хокуклар, бер үк вакытта санлы финанс активларын һәм башка санлы хокукларны, утилитар санлы хокуклар һәм санлы валюта (алар булганда) турында хәбәрнамәләр тапшыра, Россия Федерациясе Президентының "Санлы финанс активлары, санлы валюта һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында "Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары хакында" 2020 елның 10 декабрендәге 778 номерлы Указына 1 нче кушымта нигезендә форма буенча.

2. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Советының 2016 елның 23 апрелендәге 25 номерлы карары белән расланган "Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлегендә муниципаль вазыйфалар биләүне дәгъвалаучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук, Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлегендә муниципаль вазыйфалар биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында" нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

8 пунктның «3» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«үз чыгымнары, шулай ук, хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (җыелма) капиталларындагы катнашу өлеше, санлы финанс активлары, хисап чорында санлы валюта (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) сатып алу буенча һәр алыш-биреш буенча чыгымнары турында белешмәләр, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) алыш-биреш башкарылганчы соңгы өч елдагы гомуми кеременнән һәм алыш-биреш башкарылган акчаларны алу чыганакларыннан артып китсә».

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Советының 2017 елның 31 июлендәге 58 номерлы карары белән расланган "Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва итүче гражданнар һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан үзләренең, хатынының(иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакында" нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

4 пунктны түбәндәге редакциядә «в» пунктчасы белән тулыландырырга:

«үз чыгымнары, шулай ук, хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (җыелма) капиталларындагы катнашу өлеше, санлы финанс активлары, хисап чорында санлы валюта (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) сатып алу буенча һәр алыш-биреш буенча чыгымнары турында белешмәләр, әгәр

мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) алыш-биреш башкарылганчы соңгы өч елдагы гомуми кеременнән һәм алыш-биреш башкарылган акчаларны алу чыганакларыннан артып китсә».
4. Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Советының 2017 нче елның 22 августында кабул ителгән 59 нче номерлы карары белән расланган «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Түбән Бәрәскә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларына «Түбән Бәрәскә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны һәм контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, милек һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү тәртибе"нә 3 пунктның «г " пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«җир кишәрлеге, күчемсез мөлкәтнең бүтән объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (туплау) капиталларында катнашу өлеше), санлы финанс активлары, санлы валюта алу буенча алыш-биреш башкарылган чыганаклар турында белешмәләр, әгәр муниципаль вазыйфаны биләүче затның һәм аның хатынының (иренең) алыш-биреш башкарылганчы соңгы өч елдагы гомуми кеременнән һәм алыш-биреш башкарылган акчаларны алу чыганакларыннан артып китсә ».

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында (http://atnya.tatarstan.ru) урнаштырырга.

6. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җавапчылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Әтнә муниципаль районы
Түбән Бәрәскә авыл җирлеге башлыгы: Фатыхова А.В.

Совет Нижнебересканского сельского поселения
Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Советы